| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КОНОВАЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ КОНОВАЛОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге составына кергән Тупач торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2019 ел, 24 ноябрь** **№ 5**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

- чишмәне ремонтлау ( күперчекне ремонтлау, күперчеккә килү юлын төзәтү, вакт таш сатып алу)

-Тупач авылында санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү, буртлау һәм чүп-чарны чыгару.

-Тупач авылында юл читләрен чабу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 182 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе” позициясе өчен 98 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“Юк” позициясе очен __ җыенда катнашучы тавыш бирде.

1. Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

2.“2020 елда Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Коноваловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән, баачак инвалидларыннан тыш) 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны танырга һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- чишмәне ремонтлау ( күперчекне ремонтлау, күперчеккә килү юлын төзәтү, вакт таш сатып алу)

-Тупач авылында санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү, буртлау һәм чүп-чарны чыгару.

-Тупач авылында юл читләрен чабу.

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Коноваловка авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ С.А.Билалова.
(имза) (тулысынча имза)

Коноваловка авыл җирлеге Башлыгы, __________ С.А.Билалова .
Совет рәисе (имза) (тулысынча имза)